ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы референдумына чыгару өчен тәкъдим ителә торган мәсьәләнең законнарга туры килүен тикшерү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы референдумын үткәрү буенча инициатив төркем тарафыннан тәкъдим ителгән «Сез Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан куәтләре елына 40 000 тоннадан артык калдыклар белән эш итү (бөтен төр калдыклар) объектларының, шул исәптән сортларга бүлү комплексларының (станцияләренең), экотехнопаркларның, пиролиз технологиясе буенча эшкәртү предприятиеләренең, чүп ягу заводларының (җайланмаларының), зарарсызландыру җайланмаларының, калдыкларны күмү полигоннарының яңаларын төзү һәм гамәлдәгеләрен киңәйтү турында мәсьәләләрне тиешле муниципаль берәмлекләрнең җирле референдумнарына мәҗбүри чыгаруны күздә тота торган хокукый актларны кабул итәргә кирәк дип саныйсызмы?» дигән мәсьәләне «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм аларның референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясына һәм «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына туры килми дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 11 июле
№ 2977-V ДС